# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Аю авыл җирлеге Дружба торак пунктында гражданнар
җыены нәтиҗәләре турында

**20.11.2023 ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ЗРТ атарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 20 ноябрендә гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде: 2024 елда Минзәлә муниципаль районының Аю авыл җирлеге Дружба торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертергә ризамы,1,2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан, мобилизацияләнгәннәр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү:

1) Дружба торак пунктында Тапиков урамында су белән тәэмин итү челтәрләрен төзү (траншеяләр эшләү, торбалар салу, килешү буенча эш өчен түләү);
2) Дружба торак пунктында су күтәрү торбасы, насос һәм насос станциясе төзелеше белән разведка-эксплуатация скважинасын бораулау (килешү буенча эш өчен түләү).

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 99 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 50 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенының 50 катнашучысы “РИЗА” позициясе өчен тавыш бирде;

"КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Минзәлә муниципаль районының Аю авыл җирлеге Дружба торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. Сорау буенча карар кабул итегелде дип танырга:2024 елда Минзәлә муниципаль районының Аю авыл җирлеге Дружба торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертергә ризамы,1,2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан, мобилизацияләнгәннәр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү:

1) Дружба торак пунктында Тапиков урамында су белән тәэмин итү челтәрләрен төзү (траншеяләр эшләү, торбалар салу, килешү буенча эш өчен түләү);

2) Дружба торак пунктында су күтәрү торбасы, насос һәм насос станциясе төзелеше белән разведка-эксплуатация скважинасын бораулау (килешү буенча эш өчен түләү).

3. Аю авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ menzelinsk.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Аю авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районының
Аю авыл җирлеге башлыг_____________________________А. М. Ғалимов
(имза)